РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

***Постановление*** ***Карар***

**12.12.2019** **г. Чистополь** **№241**

Чистай шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан
2016 елның 27 июнендә расланган
«Стационар булмаган сәүдә
объектларының урнашу схемалары»
турындагы 96 нчы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында»гы 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясына таянып, «Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү һәм раслау тәртибе турында”гы 2011 елның 26 февралендәге 34-ОД номерлы Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 августындагы «Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә, яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында”гы 553 нче карарына нигеләнеп, «Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында”гы 2017 елның 18 сентябрендәге 675 нче карарына нигеләнеп, Чистай шәһәр Башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

1. Чистай шәһәре Башкарма комитетының «Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында»гы 2016 елның 27 июнендә 96 номеры белән расланган карары схемасына өстәмәләр кертергә, кушымта нигезендә 86-87 пунктларны өстәргә.
2. Әлеге карарны Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Ф.М. Садыйковка йөкләргә.

Шәһәр Башкарма комитеты
җитәкчесе И.Ф. Рәхимов

Чистай шәһәре
Башкарма комитетының
2019 елның 12 декабрендәге
№ 241 нче карарына
кушымта

Чистай муниципаль районының Чистай шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасы

| № т/н | Стационар булмаган сәүдә объектының урнашу урыны | Сатыла торган товарның ассортименты | Стационар булмаган сәүдә объекты төре | Сәүдә урыннары саны | Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру вакыты |
|---|---|---|---|---|---|
| 86. | Чистай шәһәре, К. Маркс ур., 92 Б адресы буенча урнашкан сәүдә комплексына якын территория | азык-төлек товарлары | сәүдә ноктасы | 2 | ел дәвамында |
| 87. | Чистай шәһәре, К. Маркс ур., 92 Б адресы буенча урнашкан сәүдә комплексына якын территория | азык-төлек булмаган товарлар | сәүдә ноктасы | 2 | ел дәвамында |